**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**<u>Сарман авыл җирлеге</u>**
**423350 Сарман авылы, М.Жэлил ур.,63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**

**E - mail: Sarman-SP@rambier.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**<u>Сармановское сельское поселение</u>**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля,63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sarman-SP@rambier.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
01.04. 2016 года № 4

Сарман авыл җирлегендә язгы 2016 елгы ташуның тискәре нәтиҗәләрен киметү, кисәтү һәм бетерү буенча

2016 елның язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, халыкны, торак, хуҗалык объектларын, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне саклау максатларында

карар бирәм:

1. Авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма, агрофирмалар җитәкчеләренә 2016 елгы язгы ташуның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә, язгы ташуга каршы чараларны гамәлгә ашыру өчен резерв материаллар һәм финанс чаралары булдыруны тәкъдим итәргә.

2. Объект җитәкчеләренә, административ һәм торак биналарның милекчеләренә үз карамагындагы объектларның, инженер-коммуналь челтәрләрнең, су үткәрү торбаларының һәм су бүлү каналларының бозларын вакытында кардан һәм боздан чистартуны, биналарның түбәләреннән карны үз вакытында чистартуны оештырырга.

3. Кичектергесез авария-торгызу эшләрен башкару очрагына инженерлык, юл-төзелеш һәм башка техниканың әзерлеген тәэмин итү буенча чаралар үткәрергә.

4. Җаваплы затларның һәм махсусларның дежур тору графигын расларга. 2016 елгы язгы ташу чорына плотинада саклануны тәэмин итү буенча техниканы карарга.

5. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында", PRAVO.TATARSTAN.RU (Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Хәсәнов И.Я.